# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## "Кама Аланы" махсус икътисадый зонасы турында

Әлеге Закон Татарстан Республикасы Түбән Кама районының Кама Аланы эшчеләр поселогында Махсус икътисадый зона төзүнең, аның эшчәнлегенең, аны бетерүнең хокукый, икътисадый һәм оештыру нигезләрен билгели һәм конкуренциягә сәләтле продукция җитештерү һәм халыкны эш белән тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итү өчен инвестицияләр, технологияләр җәлеп итү нигезендә Кама Аланы эшчеләр поселогының үз-үзен җитәрлек дәрәҗәдә икътисадый тәэмин итүенә юнәлдерелгән.

### 1 статья. Махсус икътисадый зона төшенчәсе һәм аны төзү максатлары

"Кама Аланы" махсус икътисадый зонасы дигәндә Татарстан Республикасы Түбән Кама районы территориясенең Кама Аланы эшчеләр поселогының административ чикләре белән чикләнгән бер өлеше аңлашыла, анда "Кама Аланы" махсус икътисадый зонасында катнашучылар буларак теркәлгән һәм шул зонада эшкуарлык, инвестиция эшчәнлеге алып бара торган үзебезнең ил һәм чит ил

инвесторларына бирелүче эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлегенең, гомуми режим белән чагыштырганда, махсус, ташламалы, хокукый режимы билгеләнә.

Әлеге Законда үз-үзен җитәрлек дәрәҗәдә икътисадый тәэмин итү дигәндә Кама Аланы эшчеләр поселогы җирле үзидарәсе бюджетының керем өлеше күләмен түбәндәгеләр өчен тәэмин итү аңлашыла:

- барлык дәрәҗәдәге бюджетлардан тулысынча яисә өлешчә финансланучы тармакларны агымдагы тоту чыгымнарын каплау өчен;

- "Кама Аланы" махсус икътисадый зонасының алга таба социаль икътисадый үсеше өчен.

"Кама Аланы" махсус икътисадый зонасында теркәлгән юридик затлар, шулай ук индивидуаль эшкуарлар "Кама Аланы" махсус икътисадый зонасында катнашучылар булып торалар.

"Кама Аланы" махсус икътисадый зонасында катнашучылар реестрында теркәлгән юридик затлар, шулай ук индивидуаль эшкуарлар "Кама Аланы" махсус икътисадый зонасы катнашучылары була. "Кама Аланы" махсус икътисадый зонасында катнашучыларны теркәү тәртибе һәм шартлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслый торган нигезләмә белән билгеләнә.

**2 статья. "Кама Аланы" махсус икътисадый зонасында эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген хокукый җайга салу**

"Кама Аланы" махсус икътисадый зонасында эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген хокукый җайга салу Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Закон, шулай ук Татарстан Республикасы

территориясендә гамәлдәге башка төрле норматив хокукый актлар белән гамәлгә ашырыла.

**<u>3 статья.</u> "Кама Аланы" махсус икътисадый зонасында таможня режимы һәм валюта җайга салуы**

"Кама Аланы" махсус икътисадый зонасында таможня режимы Россия Федерациясенең таможня турындагы законнары белән урнаштырыла һәм җайга салына.

"Кама Аланы" махсус икътисадый зонасында валюта операцияләрен җайга салу Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

**<u>4 статья.</u> "Кама Аланы" махсус икътисадый зонасы белән идарә итү**

"Кама Аланы" махсус икътисадый зонасы белән Кама Аланы эшчеләр поселогы җирле үзидарәсе башлыгы (алга таба - "Кама Аланы" махсус икътисадый зонасы администрациясе) идарә итә.

"Кама Аланы" махсус икътисадый зонасына идарә итү буенча "Кама Аланы" махсус икътисадый зонасы администрациясе эшчәнлеген тикшереп торуны "Кама Аланы" махсус икътисадый зонасының Күзәтчелек советы гамәлгә ашыра, аның составына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм идарәсенең республика һәм җирле органнары вәкилләре, Түбән Кама районы һәм Түбән Кама шәһәре хакимияте башлыгы, Кама Аланы эшчеләр поселогы җирле үзидарәсе башлыгы керә. "Кама Аланы" махсус икътисадый зонасы Күзәтчелек советының персональ составын Татарстан Республикасы Министрлар

кабинеты раслый.

"Кама Аланы" махсус икътисадый зонасының Күзәтчелек советы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты раслый торган Нигезләмә нигезендә эш итә.

"Кама Аланы" махсус икътисадый зонасы администрациясе ел саен, киләсе хисап елының беренче апреленнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына "Кама Аланы" махсус икътисадый зонасының узган чордагы эшчәнлеге нәтиҗәләре хакында хисап бирә.

**5 статья.** **"Кама Аланы" махсус икътисадый зонасы администрациясенең төп вазыйфалары**

"Кама Аланы" махсус икътисадый зонасы администрациясенең төп вазыйфалары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

"Кама Аланы" махсус икътисадый зонасын үстерүнең "Кама Аланы" махсус икътисадый зонасы Күзәтчелек советы раслый торган программасын эшләүне оештыру һәм әлеге программаны гамәлгә ашыру;

шушы зонада катнашучылар белән "Кама Аланы" махсус икътисадый зонасында эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге алып баруга шартнамәләр төзү һәм аларның үтәлешен тикшереп тору;

инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен үзебезнең ил һәм чит ил инвестицияләрен җәлеп итүне координацияләү.

Татарстан Республикасының "Кама Аланы" махсус икътисадый зонасында урнашкан, республика һәм коммуналь милкендә булган дәүләт милкәте, шул исәптән хуҗалык җәмгыятьләренең (ширкәтләренең) устав капиталларындагы дәүләт өлешләре (акцияләр па-

кетлары) белән идарә итү һәм аның белән эш итү вәкаләтләре милекче билгеләгән чикләрдә һәм тәртиптә "Кама Аланы" махсус икътисадый зонасы администрациясенә бирелә.

**6 статья. "Кама Аланы" махсус икътисадый зонасында эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру**

"Кама Аланы" махсус икътисадый зонасында катнашучылар үз эшчәнлекләрен законнарда билгеләнгән тәртиптә, "Кама Аланы" махсус икътисадый зонасындагы махсус режимны исәпкә алып, әлеге Закон нигезендә гамәлгә ашыралар.

"Кама Аланы" махсус икътисадый зонасында атом энергетикасы предприятиеләрен торгызуны күз алдында тотучы икътисадый проектлар гамәлгә ашырылырга тиеш түгел.

"Кама Аланы" махсус икътисадый зонасы территориясендә эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге шартнамәчел нигездә алып барыла. "Кама Аланы" махсус икътисадый зонасында эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге алып баруга "Кама Аланы" махсус икътисадый зонасы администрациясе белән анда катнашучылар арасындагы шартнамәдә законнар һәм әлеге Закон максатлары, бурычлары нигезендә якларның хокуклары һәм үзара йөкләмәләре беркетелә.

Әлеге Закон таләпләрен бозу ачыкланган очракта "Кама Аланы" махсус икътисадый зонасында катнашучылар үз статусларыннан мәхрүм ителәләр һәм реестрдан төшереп калдырылалар.

"Кама Аланы" махсус икътисадый зонасы администрациясе ачыкланган хокук бозуларны бетерү өчен "Кама Аланы" махсус икътисадый зонасында катнашучының статусын алты айга кадәр туктатып торырга хокуклы. Әлеге шарт үтәлмәгән очракта "Кама

Аланы" махсус икътисадый зонасында катнашучылар үз статусларыннан мәхрүм ителәләр.

**7 статья. "Кама Аланы" махсус икътисадый зонасында салым салу**

"Кама Аланы" махсус икътисадый зонасында катнашучылар, физик затлардан керем салымыннан, җир өчен түләүләрдән, Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы бүлегенә түләүләрдән гайре, Татарстан Республикасы бюджетына кертелүче суммалар чикләрендә барлык төр салымнар түләүдән, Татарстан Республикасы бюджеттан тыш фондларына түләүләрдән һәм дәүләт социаль һәм медицина иминияте фондына акча күчерүләрдән азат ителәләр.

Әлеге өстенлекле ташламалар исемлекләрендәге уртача санның 70 проценттан артыграгын Кама Аланы эшчеләр поселогында яшәүчеләр тәшкил иткән "Кама Аланы" махсус икътисадый зонасында катнашучыларга бирелә.

"Кама Аланы" икътисадый зонасы территориясендә әлеге Закон максатлары һәм бурычлары кысаларында эшчәнлекнең билгеле бер төрен оештыру йөкләмәләре алынган шартларда "Кама Аланы" махсус икътисадый зонасында эшкуарлык эшчәнлеге алып барганда һәм инвестицияләрне гамәлгә ашырганда "Кама Аланы" махсус икътисадый зонасында катнашучыларга салым ташламалары һәм башка өстенлекле ташламалар бирелә.

Әлеге өстенлекле ташламалар зонада катнашучыларга бары тик "Кама Аланы" махсус икътисадый зонасы территориясендә башкарылучы эшчәнлек өлешендә генә, һәм бары тик әлеге территори-

ядә фактта башкарылган инвестицияләр өлешендә генә бирелә.

"Кама Аланы" эшчеләр поселогының үзен җитәрлек дәрәҗәдә икътисадый тәэмин итү этаплап, әлеге Законны гамәлгә кертү көненнән өч елдан соң, ел саен дотацияләрне 10 процентка киметеп ирешелә.

## <u>8 статья.</u> "Кама Аланы" махсус икътисадый зонасын үстерү фонды

"Кама Аланы" махсус икътисадый зонасының икътисадый программаларын финанслау өчен "Кама Аланы" махсус икътисадый зонасын үстерү фонды гамәлгә куела.

"Кама Аланы" махсус икътисадый зонасын үстерү фонды түбәндәгеләр исәбеннән төзелә:

"Кама Аланы" махсус икътисадый зонасында катнашучы булларак теркәлгән өчен алына торган җыемнар;

җирле бюджеттан бүленеп бирелүче акчалар;

үз илебез һәм чит ил инвесторларының администрация тарафыннан шартнамәчел нигездә инвестцияләр рәвешендә җәлеп ителүче акчалары;

финанслауның законнарда тыелмаган башка чыганаклары.

"Кама Аланы" махсус икътисадый зонасын үстерү фондын төзү һәм аның эшчәнлеге тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

**9 статья.** **"Кама Аланы" махсус икътисадый зонасында җир кишәрлекләрен, җитештерү биналарын һәм корылмаларын биләү, алардан файдалану һәм алар белән эш итү хокукы**

"Кама Аланы" махсус икътисадый зонасында катнашучылар җитештерү һәм коммерция максатларын тәэмин итү өчен "Кама Аланы" махсус икътисадый зонасы территориясендә урнашкан җир кишәрлекләрен, җитештерү биналарын һәм корылмаларын биләргә, алардан файдаланырга һәм алар белән эш итәргә, шул исәптән, "Кама Аланы" махсус икътисадый зонасында инвестицияләрне гамәлгә ашыру һәм эшкуарлык эшчәнлеге алып бару шартнамәләрен исәпкә алып, аларны сату-алу һәм арендалау хокукына законнар нигезендә ия булалар.

**10 статья.** **"Кама Аланы" махсус икътисадый зонасында социаль-хезмәт мөнәсәбәтләре**

"Кама Аланы" махсус икътисадый зонасында хезмәт мөнәсәбәтләре хезмәт турындагы законнар белән җайга салына.

"Кама Аланы" махсус икътисадый зонасында катнашучылар эшкә алу һәм эштән азат итү, хезмәт һәм ял режимы, хезмәт хакын түләү һәм нормалаштыру шартлары, гарантияләр һәм компенсацияләр мәсьәләләрен мөстәкыйль хәл итәләр. Хезмәткәрләрнең хәлен хезмәт турындагы законнарда каралган шартлар белән чагыштырганда начарайту тыела.

"Кама Аланы" махсус икътисадый зонасында социаль һәм медицина иминияте һәм хезмәткәрләрне социаль тәэмин итү Татарс-

тан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнар белән җайга салына.

**11 статья. "Кама Аланы" махсус икътисадый зонасының гамәлдә булу чоры һәм зонаны бетерү**

"Кама Аланы" махсус икътисадый зонасының гамәлдә булу чоры әлеге Закон гамәлгә кергән көннән 15 ел итеп билгеләнә.

"Кама Аланы" махсус икътисадый зонасының гамәлдә булу чоры тәмамланырга алты ай кала Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты зонаны бетерү комиссиясе төзи, ә ул исә "Кама Аланы" махсус икътисадый зонасын бетерүгә бәйле барлык кирәкле гамәлләрне башкара.

"Кама Аланы" махсус икътисадый зонасын төзүнең әлеге Законда каралган максатларын һәм бурычларын үтәү йә үзен җитәрлек дәрәҗәдә икътисадый тәэмин итүгә ирешү мөмкинлеге булмаганда "Кама Аланы" махсус икътисадый зонасы Татарстан Республикасы законы нигезендә вакытыннан алда бетерелергә мөмкин. "Кама Аланы" махсус икътисадый зонасын вакытыннан алда бетерү турында Татарстан Республикасы Законы кабул ителгән очракта Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты "Кама Аланы" махсус икътисадый зонасын бетерү тәртибен һәм вакытларын билгели, шулай ук зонаны бетерү комиссиясен төзи.

**12 статья. Әлеге Законны куллануга бәйле рәвештә килеп чыгучы бәхәсләрне хәл итү**

Әлеге Законны куллануга бәйле рәвештә килеп чыгучы бәхәсләр законнарда билгеләнгән тәртиптә хәл ителәләр.

**13 статья. Әлеге Законны гамәлгә кертү турында**

Әлеге Законны матбугатта басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты алты ай эчендә әлеге Законнан килеп чыгучы хокукый норматив актлар кабул итәргә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,

1999 елның 1 декабре
№ 2469